ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КАНАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КАНАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

28.03.2018 д. Канаш №5

"Салым салу максатлары өчен исәпкә алу сәясәтен раслау турында"

РФ Салым кодексы нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан районының Канаш авыл җирлегендә 2018нче елга кушымта нигезендә салым салу максатларында исәпкә алу сәясәтен расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны авыл җирлекләренең үзәкләштерелгән бухгалтериясе баш бухгалтеры Габдрахманова Х.К. йөкләргә.

Югары Ослан муниципаль районы
Канаш авыл җирлеге башлыгы Н.Н.Вальков

Канаш авыл җирлеге башкарма комитетының
2018 елның 28 мартындагы 5 номерлы карарына
1 нче кушымта

Салым салу максатлары өчен исәп сәясәте

1. Салым исәбен алып бару баш хисапчы җитәкләгән бухгалтериягә йөкләнә.

Оешмалар табышына салым

Салым исәбен алып бару тәртибе

2. Салым исәбен алып бару өчен, салым исәбендә танылу дәрәҗәсенә бәйле рәвештә, өстәмә аналитик билгеләр ярдәмендә төркемнәргә бүленә торган бухучет күрсәткечләре файдаланыла.
Хисапта исәпкә алынмый торган операцияләр буенча Россия МНС тәкъдимнәрендә китерелгән формалар буенча салым регистрлары кулланыла. Салым исәбе регистрлары исемлеге әлеге хисап сәясәтенә кушымтада китерелгән.
Нигез: РФ Салым кодексының 313нче статьясы.

3. Керемнәрнең исәбен исәпләү ысулы белән алып барырга.
Нигез: РФ Салым кодексының 271нче статьясы.

4. Максатчан финанслау кысаларында һәм башка чыганаклардан алынган керемнәрнең аерым учетын аналитик исәпкә алу һәм салым регистрлары мәгълүматлары нигезендә алып барырга.
Нигез: РФ Салым кодексының 250нче статьясындагы 14нче пункты.

5. Салым базасын билгеләгәндә исәпкә алмаска:
- билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре (бюджет ассигнованиеләре) лимитлары; дәүләт хезмәтләре күрсәтүдән (эшләр башкарудан, дәүләт вазыйфаларын башкарудан) алынган акчалар.
Нигез: РФ Салым кодексының 251нче статьясындагы 1нче пунктының 14, 33.1нче пунктчалары.

6. Керем китерә торган эшчәнлектән салым салу максатларында керемнәр дип танyла торган керемнәр:
- учреждениегә оператив идарә хокукында беркетелгән финанс булмаган активларны гамәлгә ашырудан;
- мөлкәтне арендага бирүдән;
– РФ Салым кодексының 25нче бүлеге нигезләмәләре нигезендә шундый дип таныла торган башка керемнәр.

Сатудан кергән керемнәр һәм реализациядән тыш керемнәр РФ Салым кодексының 249нчы, 250нче статьялары нигезендә исәпкә алына.

Алынган керемнәрне түбәндәгеләр нигезендә билгеләргә:

- әйләнешләр 1.205.00.000 исәбе буенча «Керемнәр буенча исәпләүләр», табышка салым исәпләгәндә исәпкә алына торган керемнәр» аналитик билгесе;- салым регистрлары (ачыкланган артык, кире кайтарылмый торган керемнәр өлешендә һ.б.).

7. Һәр хисап (салым) чоры тәмамланганнан соң декларацияне Россия Федерациясе Салым кодексының 289 статьясында каралган срокларда бирергә.

Салым чорының бер генә хисап чорында да учреждениенең салым салынырга тиешле керемнәре булмаса, учреждение салым чоры йомгаклары буенча гадиләштерелгән рәвештә салым декларациясен тәкъдим итә (ягъни елына бер тапкыр - киләсе елның 28 мартыннан да соңга калмыйча).

Транспорт салымы

15. Салым базасын авыл җирлеге мөлкәте буларак теркәлгән барлык транспорт чаралары булу-булмаудан чыгып төзергә.
Нигезләмә: РФ Салым кодексының 28 бүлеге, “Транспорт салымы турында”гы төбәк Законы.

16. Әлеге пункт максатлары өчен, Россия законнары нигезендә транспорт чарасын исәпкә алу яисә дәүләт реестрыннан төшереп калдыру вакытына кадәр ремонттагы һәм исемлеккә кертелергә тиешле транспорт чараларын салым базасына кертергә.

Оешмалар милкенә салым

17. РФ Салым кодексының 374нче, 375нче статьялары нигезендә милеккә салым салу базасын формалаштырырга.
Нигез: РФ Салым кодексының 30нчы бүлеге.

18. Салым ставкасын регион законнары нигезендә кулланырга.
Нигез: РФ Салым кодексының 372нче статьясы.

19. РФ Салым кодексының 383 статьясында каралган тәртиптә һәм вакытларда учреждениенең урнашкан урыны буенча җирле бюджетка мөлкәткә салым һәм салым буенча аванс түләүләрен түләргә.

Җир салымы

20. Җир салымы буенча салым салу базасын РФ Салым кодексының 389нчы, 390нчы, 391нче статьялары нигезендә формалаштырырга.

Нигез: РФ Салым кодексының 31нче бүлеге.

21. Салым ставкасын РФ Салым кодексының 394 маддәсе нигезендә җирле кануннар нигезендә куллану.

22. Учреждение урнашкан урын буенча җирле бюджетка җир салымы буенча салым һәм аванс түләүләрен РФ Салым кодексының 396 статьясында каралган тәртиптә һәм срокларда түләргә.

IV. Йомгаклау нигезләмәләре

23. Исәп сәясәте турында боерыкка бухучетны оештыру өлешендә һәм салым салу максатларында үзгәрешләр бары тик ике очракта гына кертергә:
1) салымнар һәм җыемнар турындагы законнарны үзгәрткәндә исәпкә алуның кулланыла торган ысуллары үзгәргәндә;2

Нигез: 2011нче елның 6нчы декабрендәге 402-ФЗ номерлы законның 8нчы статьясы.

Беренче очракта салым салу максатлары өчен исәпкә алу сәясәтенә үзгәрешләр яңа салым чоры башыннан (киләсе елдан) кабул ителә. Икенче очракта - күрсәтелгән үзгәрешләр үз көченә кергән вакыттан иртәрәк түгел.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Канаш авыл җирлеге башлыгы Н.Н.Вальков